ЧИСТАЙ КЫРЛАРЫ

Президент Рөстәм Миңнехановның республика районнарына эш сәфәрләре дәвам итә

> 2

НӘСЕЛ ҖЕБЕ

Казанда «Без тарихта эзлебез» шәҗәрә бәйгесенә нәтиҗә ясадылар

> 2

ЛӘЛӘ КАДЕРМӘТОВА:

«Авыл хезмәтчәннәренең безнең ярдәм белән мул уңыш җыеп алачакларына ышанам»

> 3

ӨЗЕЛГӘН ҖЫР

Мәскәүдә Ренат Ибраһимовны соңгы юлга озаттылар

> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 67 (28840) | Сишәмбе | 17 май | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

САНАЛДЫЛАР

АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫН ИСӘПКӘ АЛУНЫҢ БЕРЕНЧЕ НӘТИҖӘЛӘРЕ БИЛГЕЛЕ

Мөнәсәбәт

Соңгы унбиш елда Татарстанда шәхси хуҗалыкларда мөгезле эре терлек саны кимегән. Ә гомумән Россия буенча караганда, терлекчелектә уңай динамика күзәтелә. Аның каравы татарстанлылар кошчылыкка игътибарны арттырган. Шәхси хуҗалыклар, бакчалар арткан, участоклар зурайган.

«ВТ» архивыннан

Авыл хуҗалыгында исәпкә алуның беренче нәтиҗәләре әнә шундый. Исегезгә төшерәбез: Россиядә, шул исәптән Татарстанда, узган елның августында авыл хуҗалыгын исәпкә алганнар иде. Россия һәм республика белгечләре катнашындагы «түгәрәк өстәл» вакытында әлеге зур эшнең беренче нәтиҗәләре билгеле булды. Ахыргы, тагын да төгәлрәк нәтиҗәләр исә быелның ноябрендә игълан ителәчәк. Шулай да белгечләр, күрсәткечләрдә сизелерлек зур аерма булмас, дип билгеләп узды. Нәрсә арткан, ә нәрсә кимегән соң?

Дәүләт статистикасы федераль хезмәте җитәкчесе урынбасары Константин Лайкам игълан иткән мәгълүматлар буенча, 2016 елгы исәпкә алу белән чагыштырганда, авыл хуҗалыгы оешмаларының гомуми саны кимегән. Соңгы елларда крестьян-фермер хуҗалыклары да (19 процентка), авыл хуҗалыгы җирләре дә кимегән. Күпчелек югалту терлек азыгы үстерә торган мәйданнарга туры килә.

Аның каравы Россиядә соңгы биш елда терлек саны арту күзәтелә. Бигрәк тә дуңгызчылык һәм кошчылык тармагы алга киткән.

– Гомумән алганда, нәтиҗәләр начар түгел, – дип бәяли Константин Лайкам. – Дөрес, кайвакыт шәхси хуҗалыкларның хуҗаларын сөйләштерү авыррак булды. Ләкин исәпкә алучылар эшләрен намус белән башкарды.

Дәүләт статистикасы федераль хезмәтенең Татарстан буенча территориаль органы җитәкчесе Наталья Гатауллина сүзләренә караганда, исәпкә алу статистикасы барлык төр хуҗалыклардагы игенчелек һәм терлекчелек буенча булган оператив мәгълүматлар белән тәңгәл килә.

– Ләкин без эре авыл хуҗалыгы җитештерүчеләре турындагы мәгълүматларны гына белә идек. Микроисәп барлык төр хуҗалыклар турында саннарны тупларга ярдәм итте. Бигрәк тә шәхси хуҗалыклар, бакчаларның санын ачыклый алдык. Шул ук вакытта халкы бик аз булган авыллардагы шәхси хуҗалыклар исәпкә алынмады, – дип аңлатма бирде җитәкче.

Гомуми авыл хуҗалыгы объектлары Татарстанда да кимегән. Мәсәлән, 2016 елда 745 мең авыл хуҗалыгы оешмасы булса, узган елгы нәтиҗәләр буенча, аларның саны 598 меңгә калган. Биш ел эчендә фермер хуҗалыклары да кимегән. Ә менә шәхси хуҗалыклар һәм коммерцияле булмаган ширкәтләр, ягъни бакчалар саны арткан. 2016 ел белән чагыштырганда, шәхси хуҗалыклар саны артса да, маллар үстерү кимегән. 422 меңнән артык хуҗалыкта 277,3 мең баш мөгезле эре терлек асрыйлар. Шуларның 99,5 меңе – сыерлар.

Гомумән алганда, Наталья Гатауллина соңгы унбиш елда шәхси хуҗалыкларда мөгезле эре терлек саны кимүен әйтте.

– Без гомумроссия күрсәткечләреннән шушы позициядә генә аерылабыз, – диде ул. – Аның каравы Татарстанда кошчылык тармагы 2–2,1 тапкыр үскән. Терлек саны кимесә дә, малларның продуктлылыгы арту күзәтелә. 2006 ел белән чагыштырганда, тәүлеклек сөт савып алу 1,7 тапкыр арткан.

Республикада да авыл хуҗалыгы җирләренең авыл хуҗалыгы әйләнешеннән төшеп калуы күзәтелә. Шул ук вакытта фермер хуҗалыгы җирләре арткан, шул исәптән чәчүлек мәйданнары да. Исәпкә алу нәтиҗәләре шәхси хуҗалык участокларының да уртача биләмәләре артуын күрсәткән.

– Исәпкә алу барышында үзебез өчен ачыш ясадык. Республиканың ике районында тәвә кошы үрчетүләре һәм 13 районда әстерхан чикләве үстерүләре билгеле булды, – диде Наталья Гатауллина.

Татарстан Премьер-министры урынбасары Ләйлә Фазлыева әйтүенчә, авыл хуҗалыгын исәпкә алу барышында алынган нәтиҗәләр бик мөһим.

– Авыл хуҗалыгын үстерү дәрәҗәсе югары булганда гына төбәк икмәк-тозлы була ала. Ә Татарстан өчен бу өстенлекле тармак булып тора. Шуңа күрә нәтиҗәләр безгә югары уку йортларында белгечләр әзерләүгә дә, Россия тәкъдим итә торган ярдәм чараларына да, электрон мәйданчыкларда эшләүгә дә йогынты ясаячак. Ә авыл хуҗалыгында кредитлар һәм субсидияләр мөһим урын алып тора. Шулай ук әлеге мәгълүматлар фән өчен дә, демографиягә дә бик кирәк, – диде Ләйлә Фазлыева.

Зөһрә САДЫЙКОВА

Без – өченче урында

Татарстан социаль-икътисади вазгыять буенча иң яхшы өч төбәк арасына кергән. Узган ел йомгаклары буенча республика барлыгы 77,616 балл (2020 ел йомгаклары буенча – 69,263) туплаган. Татарстанны Мәскәү (89,948) һәм Санкт-Петербург (86,064) шәһәрләре генә узган. Дүртенче урында – Мәскәү өлкәсе (77,333), Ханты-Манси автономияле округы (76,468) бишенче булган.

Рейтинг нәтиҗәләре социаль-икътисади хәлнең тулаем яхшыруын күрсәтә. 2021 ел йомгаклары буенча барлыгы 81 субъектның рейтингы үскән. Шул ук вакытта Татарстан хезмәт хакы үсү буенча төбәкләр рейтингында 34 нче урынга чыккан. Республикада соңгы биш ел эчендә эш хакы елына уртача 8 процентка арткан. Эшләр болай барса, бер чама акча алып эшләүчеләрнең уртача хезмәт хакы кимендә 13 елдан соң гына 100 мең сумга җитәчәк.

Кунаклар күбрәк килгән

Майның беренче ун көнендә Казанда 200 мең турист булып киткән. Шәһәр мэриясеннән хәбәр ителгәнчә, узган елдагыга караганда 50 меңгә күбрәк сан бу. Татарстанның май бәйрәмнәрендә сәяхәтчеләр өчен иң популяр юнәлешләрнең берсенә әйләнүе турында «Ростуризм» башлыгы Зарина Догузова сөйләп үткән. Исемлеккә шулай ук Калининград, Мәскәү, Ярославль, Владимир өлкәләре, Санкт-Петербург, Мәскәү шәһәрләре, Краснодар һәм Ставрополь крайлары кергән.

Кунакханәләр ассоциациясе мәгълүматлары буенча, 30 апрель – 9 май аралыгында республика башкаласы кунакханәләре 85 процентка тулган. Туристлар бигрәк тә өч йолдызлы кунакханәләрне (92 процент) үз иткән. Шул ук вакытта, соңгы тикшеренүләрнең берсенә караганда, Татарстанда яшәүчеләрнең күпчелеге май бәйрәмнәрен өйләрендә генә үткәргән. Сәяхәтчеләребезгә килсәк, 20 проценты чамасы Санкт-Петербург һәм Мәскәүне сайлаган. 40 проценттан артыграгы күрше төбәкләргә: Самара һәм Ульяновск өлкәләренә, Башкортстан, Чуашстан һәм Мари Иленә өстенлек биргән.

Бәйрәм гадәттәгечә узачак

Россия Мәгърифәт министрлыгы мәктәпләргә «Соңгы кыңгырау» бәйрәмен һәм чыгарылыш кичәләрен онлайн түгел, бәлки гадәттәгечә – җанлы итеп уздыру тәкъдимен җиткергән. «Соңгы кыңгырау»ны мәктәп расписаниесенә карап үткәрергә тәкъдим итәбез. Гадәттә ул май ахырында: кайдадыр – 25ендә, кайдадыр алданрак уза», – дигән ведомство башлыгы Сергей Кравцов. Ә инде чыгарылыш кичәсен 25 июньдә уздыру тәкъдим ителә. Министр әйтүенчә, чыгарылыш кичәләрен шушы көнне үткәрү – мәгариф системасы традициясе. Шуңа күрә бу бәйрәм, шулай ук «Соңгы кыңгырау» барлык мәктәпләрдә узачак.

Сүз уңаеннан, Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыгы 9 нчы һәм 11 нче сыйныфны тәмамлаучылар өчен 24 майда соңгы кыңгырау яңгыраячагын белдерде. Ә инде чыгарылыш кичәләрен 24 июньнән алданрак үткәрмәскә тәкъдим ителде.

Актуаль тема

Алганчы җиде кат уйлыйсы

Соңгы арада Россиядә кредит каникулыннан файдаланучылар саны арткан. Аналитиклар китергән саннарга ышансаң, апрель аенда гына да илдә 6 меңләп кеше кредит каникулы алган. Чагыштыру өчен: март аенда бу мөмкинлектән 1,2 мең кеше файдаланган булган. Коронавирус котырган пандемия чорында исә андыйлар саны 4 меңнән артып киткән.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Кредит каникулы килеп туган вазгыять аркасында матди авырлык кичергән кешеләрнең кредит буенча айлык түләвен 6 айга кадәр кичектереп тору яки аның күләмен киметүне күздә тота. Ул соңгы елларда аеруча популяр. Хәтерләсәгез, пандемия чорында матди авырлык кичергән кешеләргә дә кредит буенча айлык түләүләрен вакытлыча кичектереп торырга рөхсәт иткәннәр иде. Быелның март башында Россия Президенты Владимир Путин кредит каникулы турында яңа закон имзалады. Ул быел 1 мартка кадәр рәсмиләштерелгән барлык төр кредитларга кагыла. Аннан пандемия чорында кредит каникулы алган кешеләр дә файдалана ала.

Билгеле булганча, быелның мартыннан кредит каникулын ипотека түләүчеләр генә түгел, машина яки кулланучы кредиты алган, кредит картасына ия булучылар, пандемия вакытында бу мөмкинлекне бер тапкыр кулланып караган кешеләр дә файдалана ала. Кече һәм урта эшмәкәрлек тармагы вәкилләре өчен дә гамәлдә ул. Соңгы бер ай эчендә илдә кредит каникулы алучылар саны кискен артуны белгечләр килеп туган вазгыятькә бәйләп аңлата.

Юрист Илнур Гарифуллин кредит каникулыннан файдаланыр алдыннан, җиде кат уйлап, бер кат кисәргә киңәш итә. «Каникул алган кешенең автомат рәвештә кредит тарихы бозыла. Бу исә киләчәктә яңа кредит алырга туры килсә яки булган кредитны рефинансларга уйласаң, кыенлыклар килеп чыгарга мөмкин дигән сүз. Кредит каникулыннан файдаланган кеше, ким дигәндә, ярты ел дәвамында яңа кредит рәсмиләштерә алмаячак. Ник дигәндә, бу еллар сезнең айлык түләүләрне вакытында түләп бара алуыгызны шик астына куя», – ди юрист.

Кредит каникулыннан билгеле бер суммага кадәр кредит алган кешеләр генә файдалана ала. Ипотека кредиты өчен бу чик – 2 миллион сум, автокредит өчен – 600 мең сум, шәхси эшмәкәрләргә куллану кредиты өчен – 300 мең сум, физик затларга куллану кредиты өчен – 100 мең сум, физик затларның кредит карталары буенча 100 мең сум тәшкил итә. Моннан тыш, кредит каникулы бирүне сорап мөрәҗәгать иткән көнгә бер ай кала кешенең айлык керемнәре, ким дигәндә, 30 процентка кимегән булырга, исемендә түләнеп бетмәгән башка кредитлар булмаска тиеш.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

Сүзгә-сүз

Вадим УВАРОВ, Үзәк банкның мәгълүмати куркынычсызлык департаменты директоры:

Гадәттә гражданнар телефон мошенникларына акчаларын ирекле төстә күчерәләр. Үзләренең алданулары берникадәр вакыт үткәч кенә аңлыйлар. Әмма акчаны кайтарырга инде соң була. Аларның мәнфәгатен саклау йөзеннән, без счетка акча күчерүне мәҗбүри төстә ике көнгә туктатып тору гамәлен кертергә телибез. Бу вакыт аек баштан уйлау, үз гамәлләренә бәя бирү өчен кирәк.

«Известия» газетасына биргән әңгәмәдән

ТАТАРСТАНДА – ЯЗГЫ ЧӘЧҮ

Республикада язгы чәчү эшләренең яртысыннан артыгы тәмамланган. 16 майга булган мәгълүматларга караганда, 1,8 миллион гектарның 1 миллионнан артыгы чәчелгән. Бу – планның 56 проценты.

Бодай – 432,3 мең га	50%
Арпа – 445,4 мең га	81%
Солы – 49,6 мең га	69%
Шикәр чөгендере – 49,3 мең га	79%

Атна ахырында кырау көтелә

Республикада атна уртасына кадәр җылы, әмма яңгырлы-яшенле һава саклана. Шуннан соң берникадәр суыта, яңгыр туктый. Җомга һәм шимбә көннәрендә кырау төшәргә мөмкин. Татарстан Гидрометеоүзәгеннән хәбәр ителгәнчә, чәршәмбе – 18 майда һәм пәнҗешәмбе – 19 майда Татарстанда салкынча һава хөкем сөрәчәк. Чәршәмбе көнне көндез +10…+15 градустан артмаячак, төнлә +3…+8 градус булачак. Секундына 15–18 метр тизлектә җил.

Башлангыч фаразларга караганда, җомга – 20 май һәм шимбә – 21 майда яңгырлы суык һава көтелә. Көндез +7…+12, төнлә +1…+6 градус. Урыны белән кырау төшәргә мөмкин.

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

ЯҢА БИЗГӘК КУРКЫНЫЧЫ ЯНЫЙМЫ?

Дөнья сәясәтендә һәм икътисадында вакыйгалар кызган табадагы борчаклар кебек сикерешә. Кызганыч ки, кызу хәбәрләрдән уңай мизгелләрне табып алу мөкин түгел диярлек. Рәсми яңалыклар безне глобаль ачлык перспективасы белән куркыталар, икътисади түнтәрелеш бөтен почмаклардан хәбәр сала, инфляция гиперинфляциягә әйләнү куркынычы белән яный, яңа хәрби конфликтлар өчен оеткы салына. Дефолт игълан иткән Шри-Ланкадан дәһшәтле хәбәрләр алына: ач халык бай чиновникларга һәм сәясәтчеләргә һөҗүм итә, виллаларны юк итәләр, автомобильләр суга ташлана, полиция дәүләт хезмәткәрләренә куркыныч тудырган гражданнарны урынында ата, диләр. Шри-Ланка киләчәк дөньякүләм вазгыятьнең миниатюрасы булмасын иде, дип телик. Әмма хәл бик катлаулы. Дәүләтләр яңа аркадашлар эзли: кичәге дошманнар бүген дуска әйләнә, дуслар арткы яктан пычак кадыйлар.

2018 елда гарәп журналисты Җәмәл Хашогги Төркиядәге Согуд илчелегендә үтерелеп, мәете туракланып алып чыгылганнан соң, Әнкара белән Әр-Рияд арасында дошманлык башланган иде. Вашингтон белән Әр-Рияднның арасын да тәмам бозып бетерде ул хәл. Бүгенге сәясәттә гарәпләр, АКШка үч итеп, Россия өчен файдалы адымнар ясый икән, аның чүпрәсе менә шул 2018 елда салынды. Сыгылмалы сәясәт алып бару остасы Әрдоган Согуд Корольлеге белән мөнәсәбәтләрне җайлап, яңа аркадашлык башлап җибәрде. Аның корольлеккә визиты бик бәрәкәтле булырга охшаган. Ә менә Россия өчен бу якынаю нинди кайтаваз бирер, әлегә әйтү кыен. Газета хәбәрчесе төрек – гарәп аркадашлыгы якын перспективада Россиягә каршы борылырга мөмкин дип тә фаразлый. Якын Көнчыгышта зур азык-төлек кытлыгы булдыра калсалар, көнбатышлылар ачлыкта Россияне гаепләячәкләр. Хәзер үк гаеплиләр инде. Финляндия белән Швециянең НАТОга таба адымнары болай да Россиянең көнбатыш чикләрендә киеренкелекне арттыра. Якын Көнчыгышның нефть һәм газ державаларын да Россиягә каршы бора алсалар, вазгыять Мәскәү өчен оттырышлыга әвереләчәк. Төрекләрнең Хашогги «өрәге»н сандыкка салып куеп, гарәпләр белән яңа аркадашлык башлавы – җитди сигнал.

Кытайда вазгыять авырлаша. Икътисади проблемалар фонында Азия гигантының үз эчендә лидерларның күзгә күренмәгән тартышы бара, диләр. Илнең хәзерге лидеры Си Цзинпиньга каршы Дәүләт Советының гамәлдәге Премьеры Ли Кэцяну яңа полюс формалаштыра дигән хәбәрләр ишетелә. Соңгысы – либераль сәясәт тарафдары, икътисадта да, илнең эчке тормышында да гайкаларны бушатуны яклый икән. Кытай комсомолы лидерлыгыннан югары сәясәт баскычына сикергән Лины югары эшелонда яклаучылар күп, ди. Көзен Кытай компартиясенең XX съезды көтелә. Илдәге авыр икътисади вазгыять фонында Си Цзинпинь үз хакимлеген саклап, өченче срокка кала алырмы? Дилемма менә шулай куелган. Ли Кэцянуны лидерлыкка күтәрсәләр, Россия – Кытай мөнәсәбәтләрендә уңайсыз үзгәрешләр булырга мөмкин.

Дөньяның барлык почмакларын менә шундый сәяси һәм икътисади бизгәк тота. Май башында Төньяк Корея үзендә яңа куркыныч чир таралуы – йөз меңләгән кешенең сәер бизгәк белән чирләве турында игълан итте. Үлүчеләр дә бар. Чынлап та яңа чир чыкканмы, әллә коронавирусның яңа штаммы гына тараламы, әйтү кыен. Пекинда яңа штамм турында сүз алып баралар. Төньяк Корея – бикле ил, шул сәбәпле яңа чир турында мәгълүмат аз.

Россиядә

БАСЫМ КӨЧӘЯ, ӘММА БЕЗ ТҮЗӘБЕЗ

Россиянең эчке тормышы тышкы дөнья басымы тәэсирендә формалаша. Әйе, товар җыю шаукымы туктады, яңа паника кубару өчен кесәләрдә акча юк. Федераль финанс хакимиятләре инфляцияне гиперинфляциягә әйләндерми кала алдылар дип әйтерлек. Бюджет рекордлы дәрәҗәдә профицитлы, туры мәгънәсендә акчаны куярга урын юк. Яңа проектлар башлар идең, технологик җиһазларны кайдан аласың? Акчаны халыкка өләшер идең, бәяләрнең куәтле күтәрелеше белән кайтаваз бирәчәк. Ул кайтавазны импорт белән басып булмаячак инде. Банклар арзанлы доллар сата башладылар, ажиотаж юк. Доллар түгел, көндәлек кирәккә сумнарны да җиткереп булмый әле монда. Россия компанияләренең 64 проценты яңа хезмәткәрләр яллауны туктаттылар, диләр. Массакүләм эштән кыскартулар юк. Эш бирүчеләрнең 21 проценты гына кыскартулар белән мавыга икән. Гомуми юрисдикциядәге кассация суды эштән ихтыяри-мәҗбүри китүчеләрне яклый торган аңлатма ясады. Әгәр җитәкчелек сиңа үз теләгең белән эштән китәргә мәҗбүр итеп басым ясый икән, андый шартларда язылган гариза юридик көчкә ия түгел. Үз хокукларыңны яклап судлаша аласың. Гаризаны, чынлап та көчләп яздыруларын исбатлый алсаң, эш урынына кире кайту мөмкин. Иң яхшысы – җитәкчелек белән уртак тел табып, җәнҗалсыз гына эшләү инде, әлбәттә.

Әле эш урынын югалтмаган россиялеләргә дә авырга туры килә. Иске киемнәрне ямап бирү өчен ательеларга килүчеләр саны арту турында яза әнә патриотик сайтлар да. Акча күплеге, валюталар муллыгы фонындагы кытлык – моңарчы без күрмәгән вазгыять. Көнбатыш державалары исә бу вазгыятьне төзәтү белән мәш килә: Россиядә акча да булмасын, кытлык та көчәйсен дип тырышалар. G7 илләренә кергән дәүләтләрнең тышкы эшләр министрлары 12–14 майда Германиядәге Вайссенхаус замогына киңәшергә җыелдылар. Кайчандыр мондый очрашуларны G8 дип йөртүләрен, сигезенче держава Россия булуын без инде оныттык та. Зур җиделек вәкилләре, акрын җигеп, тиз китәргә ниятлиләр. Россияне нефть сату мөмкинлегеннән мәхрүм итү чаралары карала, газ сатуны чикләү дә – көн тәртибендә. Әлегә бик барып чыкмый аларның ниятләре. Тик шулай да вазгыятьнең безнең өчен отышлы булуына алданырга ярамый.

Көнбатышта хәзер 24 февральгә кадәрге чикләр турында сүз дә алып бармыйлар инде. 2014 елгы чикләрне кире кайтару максат итеп куела. Бу – Кырымны югалту, Донбассны ташлау дигән сүз. Украина заманча технологик кораллар белән актив коралландырыла. Демилитаризация урынына ашкынып кораллану мәйданга чыкты. G7 Кытайның Россиягә басым ясавын таләп итә. Бу юнәлештә уңышка ирешә алсалар, безнең хәл тагын да авырлашачак. «Сез безнең карашларны кабул итсәгез, без сезнең белән килешәбез» дигән сәясәт алып бару мөмкинлеге бетеп бара. Шуңа күрә иске киемнәрегезне ташлап ук бетермәгез.

ПРЕЗИДЕНТ КӨНДӘЛЕГЕ

tatarstan.ru

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнехановның республика районнарына эш сәфәрләре дәвам итә. Бу юлы Татарстан Президенты – Чистайда. Биредә ул кыр эшләре белән танышты, авыл хуҗалыгы тармагы предприятиеләре җитәкчеләре белән очрашты.

Район турында әйткәндә, җирлек авыл хуҗалыгы нәтиҗәлелеге рейтингында күрсәткечләрен арттыра бара. Чистай, узган елгы нәтиҗәләр буенча, 12 позициягә күтәрелеп, 22 нче урынны били. Быел авыл хуҗалыгы юнәлешенә 61,2 млн сум акча бүлеп бирергә җыеналар. Бу – республика һәм федераль бюджет акчасы. Матди ярдәм районда терлекләрнең баш санын арттыру һәм шуның нәтиҗәсе буларак сөт җитештерү юнәлешен көчәйтү өчен тотылачак. Акча малларга азык сатып алу, фермаларны төзекләндерү һәм җиһазлауга, техникага кирәк. Бу җәһәттән Татарстанның авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры Марат Җәббаров та районда баш саны кимү күренеше барлыгын искәртте. Ел азагына кадәр сыерларның санын 600 башка арттырырга вәгъдә бирде Чистай районы башлыгы Дмитрий Иванов.

Кыр эшләренә килгәндә, чәчү мәйданнарының 70 проценты инде чәчелгән. Эшләрне тәмамлау өчен бер атна кирәк.

Татарстан Президенты районда эшчеләр әзерләү мәсьәләсенә дә тукталды. Халык белән очрашуда әйтелгән тәкъдим-фикерләрнең дә үтәләсен вәгъдә итте.

Эш сәфәре кысасында Татарстан Президенты «Агро-Л» терлек комплексында булып, аның эшчәнлеге белән танышып чыкты. Предприятие сөтчелек белән шөгыльләнә. Комплекста 1 мең баш сыерга исәпләнгән 4 сыер абзары, яшь бозаулар өчен өч бина каралган. Хәзерге көндә фермада 1817 баш мөгезле эре терлек бар.

Аннан Рөстәм Миңнеханов «Чистай» индустриаль паркында булды. Ул кече шәһәрләрне үстерү программасы кысасында төзелде. 292 га территориядә 13 компания эшли.

Президентка парк эчендә эшчәнлек алып баручы «Барс» аяк киемнәре компаниясен күрсәттеләр. Сүз уңаеннан, бу предприятие Россиядә берьюлы дүрт төр махсус аяк киеме җитештерүче бердәнбер оешма санала. Компания көн саен 2,5–3 мең пар аяк киеме эшләп чыгара. 2019 елда ачылган предприятиенең табышы 931 млн сумга кадәр җиткән. Татарстанда җитештерелгән аяк киемен Россиянең башка төбәкләренә дә, чит илләргә (Казахстан, Белоруссия) дә саталар.

Барыбыз да – пионериядән

Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин Татарстанның пионерлар хәрәкәте һәм комсомол оешмалары ветераннары белән очрашты. Очрашу В.И. Ленин исемендәге Бөтенроссия пионер оешмасына 100 ел тулуга багышлап үткәрелде.

– 19 майда үткәрелүче Пионерия көне алдыннан сезне атаклы пионер оешмасының 100 еллык юбилее уңаеннан котлыйм! Аннан башка без, бөек совет иле балалары, үз балачагыбызны күз алдына да китерә алмый идек. Мин үзем дә пионер идем. Аның нинди җаваплы һәм әһәмиятле булганын беләм, – диде Фәрит Мөхәммәтшин, ветераннарны сәламләп. – Саллы «яше»нә һәм дәверләр алышынуга карамастан, Пионерия көне әлегәчә билгеләп үтелә.

Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин әйтүенчә, пионерия яшь кеше өчен һәм булачак гражданин өчен бик әйбәт мәктәп булды. Пионер оешмасы балаларда ватанга карата мәхәббәт, белемгә омтылыш тәрбияләде, аларны хезмәткә һәм иҗтимагый эшчәнлеккә җәлеп итте. «Пионерлар яшьтән үк үзләренең тормышындагы күп кенә мәсьәләләрне күмәк төстә хәл итәргә, вакытны файдалы, мавыктыргыч итеп уздырырга, өлкәннәр турында кайгыртырга, тимер-томыр һәм макулатура җыярга, агачлар утыртырга, йорт хайваннары тәрбияләргә, уңыш алырга өйрәнде. Алар комсомол оешмасы белән бергә сукбайлык һәм наданлыкны бетерүдә катнашты, авыл клублары һәм китапханәләргә шефлык итте, өмәләр үткәрде», – дип хатирәләре белән уртаклашты Фәрит Мөхәммәтшин.

Парламент җитәкчесе фикеренчә, хәзерге вакытта үсеп килүче буынны тәрбияләү һәм аның ялын оештыру буенча боларның күбесе югалды, бу юнәлештәге эшне көчәйтергә кирәк. Ул 2015 елда Россия Президенты Указы белән илдә советларның пионер хәрәкәтенә охшаш «Россия мәктәп укучылары хәрәкәте» пәйда булуын искә төшерде. «Үсеп килүче буынны тәрбияләү өлкәсендә дәүләт сәясәтен камилләштерү максатындагы хәрәкәтне республикада актив үстерергә кирәк», – диде Фәрит Мөхәммәтшин, һәм Татарстанда яшьләр катнашындагы уңышлы проектлар турында сөйләп үтте. Ул Дәүләт Советы, Мәгариф һәм фән министрлыгы оештырган «Парламент дәресе» проектын да искә төшерде.

Очрашу ахырында республиканың пионер һәм комсомол оешмалары ветераннарына Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хатлары тапшырылды.

КИЛӘЧӘКНЕ БУЛДЫРУЧЫЛАР СЕЗ

Татарстан Президенты Рөстәм МИҢНЕХАНОВның Бөтендөнья электрон элемтә һәм мәгълүмат җәмәгатьчелеге көне уңаеннан КОТЛАВЫ

Кадерле дуслар!

Сезне Бөтендөнья электрон элемтә һәм мәгълүмат бергәлеге көне уңаеннан котлыйм! Барлык программистлар, система администраторлары, интернет-провайдер, веб-дизайнер, интернет-басмалар мөхәррирләре, мәгълүмати технологияләр өлкәсенә җәлеп ителгән тагын бик күп белгечләрнең бәйрәме бу.

Сез иң тиз үзгәреп торучан, иң алгарышлы эшчәнлек өлкәсендә хезмәт куясыз. Мәгълүмати технологияләр чын мәгънәсендә цивилизациянең йөзен үзгәртә. Информатика кешелеккә элек күз алдына да китереп булмаган хәзинә тудыра: мәгълүмат һәм белем төп байлыкка әйләнеп, үзебезне үстерү өчен гаять зур мөмкинлекләр ачыла.

Татарстанда 2022 елның Цифрлаштыру елы буларак игълан ителүе очраклы түгел. Мәгълүмати технологияләрне үстерүнең Россиядә һәм бөтен дөнья күләмендә безгә көндәшлектә өстенлек бирәчәген бөтен тирәнлеге белән аңлыйбыз. Алга таба нәкъ менә IT-өлкә икътисадта этәргеч көчкә әйләнәчәк. Моның өчен бездә кирәкле барлык нигезләр: тәҗрибәле IT-компанияләр, элемтә операторлары, вузлар, стартапларга ярдәм итү һәм аларны үстерү өчен ныклы инфраструктура, профессиональ белгечләр бар.

Татарстанда IT-тармакны үстерү өчен моңарчы күрелмәгән чаралар тормышка ашырыла: Казан һәм Чаллы шәһәрләрендә IT-парклар нәтиҗәле эшли, «кIТык» республика ярдәм программасы гамәлдә булып килә, Иннополис югары технологияләр шәһәре үстерелә, Бәшир Рәмиев исемендәге технопарк һәм яңа IT-квартал төзелә.

Татарстанда булдырылучы цифрлы экосистеманың республикага меңнәрчә яшь, талантлы кешене җәлеп итәчәгенә ышанам. Сезнең белән без Татарстанны Россиядә IT-индустрияне үстерүнең әйдәп баручы үзәгенә әйләндерәчәкбез.

Хезмәтегез өчен рәхмәт белдереп, куелган максатыгызга ирешүегезне, иминлек һәм бәхет телим!

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЛАРЫ

«Сабан туе» татар халык бәйрәмен уздыру турында

2022 елда «Сабан туе» татар халык бәйрәмен үткәрү максатында һәм «Татарстан Республикасының бәйрәм көннәре һәм истәлекле даталары турында» 1992 елның 19 февралендәге 1448-XII номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясы нигезендә **карар бирәм**:

1. Җирле үзидарә органнары тәкъдимнәрен исәпкә алып, «Сабан туе» татар халык бәйрәмен түбәндәге срокларда уздырырга:

Татарстан Республикасы авыл торак пунктларында, район үзәкләрендә (шул исәптән, республика әһәмиятендәге шәһәрләрдә дә) – 2022 елның 11–13 июнендә;

Чаллы шәһәрендә – 2022 елның 18 июнендә;

Татарстан Республикасы башкаласы Казан шәһәрендә – 2022 елның 19 июнендә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына җирле үзидарә органнары белән берлектә бәйрәм чараларын күрсәтелгән срокларда уздыруны оештыруны тәэмин итәргә.

3. Җирле үзидарә органнарына, җәмәгать берләшмәләренә, предприятиеләргә, оешмаларга «Сабан туе» татар халык бәйрәмен әлеге Указда билгеләнгән вакытларда оештыруда һәм уздыруда актив катнашырга тәкъдим итәргә.

4. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль. 2022 ел, 16 май, № ПУ-334

«Каравон» рус халык бәйрәмен уздыру турында

2022 елда «Каравон» рус халык бәйрәмен уздыру максатларында һәм «Татарстан Республикасының бәйрәм көннәре һәм истәлекле даталары турында» 1992 елның 19 февралендәге 1448-XII номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясы нигезендә **карар бирәм**:

1. Җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы тәкъдимнәрен исәпкә алып, «Каравон» рус халык бәйрәмен 2022 елның 28 маенда Татарстан Республикасы Лаеш районының Никольское авылында уздырырга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына «Каравон» рус халык бәйрәмен әзерләүгә һәм уздыруга ярдәм итәргә.

3. Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына «Каравон» рус халык бәйрәмен әзерләүне һәм уздыруны массакүләм мәгълүмат чараларында яктыртуны оештырырга.

4. Җирле үзидарә органнарына, иҗтимагый берләшмәләргә һәм оешмаларга «Каравон» рус халык бәйрәмен әзерләүдә һәм уздыруда актив катнашырга тәкъдим итәргә.

5. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль. 2022 ел, 16 май, № ПУ-335

НӘСЕЛЕҢНЕ БЕЛ!

Бәйгедән соң

Республика күләмендә узган «Без тарихта эзлебез» шәҗәрә бәйгесендә катнашучылар әнә шулай ди. Галиәсгар Камал театры бинасында бәйгенең йомгаклау өлеше узды. Республика районнарыннан алты гаилә финалга узган. Театр бинасын иртәдән шаулатты алар.

Һәр гаилә кунакларның күңелен күрергә тырышты. Ризык әзерләп килгәннәр, җыр-моң өләштеләр. Әнә шулар аша гаиләләре, нәселләре белән таныштырдылар.

– Нәсел җепләрен өзмичә саклау – ата-бабаларның әманәте ул. Без шуны үтәргә тиеш. Нәселебезнең 16 буынын таптык. Моның өчен архивларда утырырга, авылдагы өлкәннәрдән сорашырга, сандык төпләреннән эзләнергә туры килде, – ди Саба районының Олы Шыңар авылыннан Ахунҗановлар нәселен дәвам иттерүче Райлә Галәвина. – Ахунҗан бабайның бишенче буын оныгы мин. Бабабыз 1868 елда Олы Шыңар авылында туа. Ул сәүдәгәр була. Хатыны Бибифатыйха белән иген игеп, мал асрап көн күргәннәр, 10 бала тәрбияләп үстерәләр. Бабам авылда кибет тоткан, күп кенә кешене ачлыктан коткарган. Әмма аны 1930 елда кулак дип сөргенгә җибәрәләр. Магнитогорск якларында үлеп кала.

Ахунҗан бабай оныклары моннан ун ел элек үзләре шәҗәрә бәйрәме ясый. Ул чакта нәселләрендә 485 кеше табыла. Хәзер алар 700 кешегә җиткән инде. Иң өлкән яшьтәге Әминә апаларына 98 яшь тула, иң нәни оныкчыкка 2 ай икән. Алар күргәзмәгә әбиләре Бибифатыйха кигән күлмәкне дә алып килгән. 150 ел чормада ятып та төсен югалтмаган ул. Оныклары исә, эзләнә торгач, нәсел агачын гына түгел, тамгасын да тапканнар. Баксаң, уч төпләрендәге сызыкларны бабалары тамга итеп алган икән. Еллар үтсә дә, сурәтләр туры килә.

Буа районының Яңа Чәчкап авылыннан Латыйповлар белән Нәгыймуллиннар гаиләләре 17 буынын эзләп тапкан. Кода-кодагыйлар берләшеп, нәсел шәҗәрәсен ясаганнар.

– Нәсел җепләрен барлау җиңел булмады. Архивларда күп утырдык. Рамил улым 6 нчы сыйныфта укыганда бер бәйгедә катнашты. Шуның өчен нәсел барлый башлаган идек. Аннары үзебез өчен булсын дип, шәҗәрә төзедек. Республика күләмендә бәйге оештырылганын белгәч, бик теләп катнаштык. Казанга барасыбызны белү тагын да канатлар куйды. Бер яктан, сөендек, икенче яктан, бу эшнең җаваплылыгын тойдык, – ди Гөлнирә Нәгыймуллина.

Дүртенче тапкыр уздырылган бәйгедә быел 42 гаилә катнашкан. Бирегә килгән алты гаиләнең дә сөйләрлек тарихы бар. Иң мөһиме – алар барысы да гаиләнең кадерен, нәселен белеп, әби-бабаларының рухын шатландырып яши.

Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин фикеренчә дә, республикада яшәүче гаиләләрнең тату булуы тәрбиядән тора.

– Әлеге бәйге традицияләрне саклауга, гаилә элемтәләрен һәм буыннар бәйләнешен ныгытуга, үз нәселенең тамырларына һәм туган як тарихына карата кызыксыну уятуга юнәлтелгән. «Без тарихта эзлебез» шәҗәрә бәйгесенең популярлыгы елдан-ел арта бара. Мондый чараларны мин бәйрәм кебек кабул итәм. Тарихны белү, нәселләрне барлау, тормыш тәҗрибәңне, гореф-гадәтләреңне буыннан-буынга тапшыру – күпмилләтле республиканың байлыгы ул. Бездә төрле милләт вәкилләре дус-тату яши, – диде ул. – Быелгы шәҗәрә бәйрәмендә катнашучылар бигрәк күңелгә кереп калды. Алар ничәшәр буынын барлап тапкан бит! Катнашучы гаиләләргә мондый олы бәйрәм ясаганнары өчен рәхмәт.

Быелгы бәйгедә Саба районыннан Ахунҗановлар нәселен дәвам иттерүчеләр җиңүче дип табылды. Буа районыннан Латыйповлар белән Нәгыймуллиннар – икенче, Бөгелмәдән Малыхиннар өченче урынга лаек булды.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

ЛӘЛӘ КАДЕРМӘТОВА:

«АВЫЛ ХЕЗМӘТЧӘННӘРЕНЕҢ БЕЗНЕҢ ЯРДӘМ БЕЛӘН МУЛ УҢЫШ ҖЫЕП АЛАСЫНА ЫШАНАМ»

Дөньяда барган вазгыять авыл хуҗалыгына да тәэсир итә. Эре җитештерүчеләр дә, зур хуҗалыклар да, фермерлар да тоя аны. Мондый шартларда нинди дәүләт ярдәменә өметләнергә була? «Россельхозбанк»ның Татарстан төбәк филиалы директоры, Дәүләт Советы депутаты Ләлә Ринат кызы КАДЕРМӘТОВА белән «ВТ» хәбәрчесе шул хакта сөйләште.

:: Ләлә Ринатовна, без сезнең белән язгы чәчү чорында очрашабыз. Быел ул катлаулы шартларда бара. «Россельхозбанк» авыл хезмәтчәннәренә сезонлы эшләргә акча белән ярдәм итү буенча – һәрвакыт алгы сафларда. Агымдагы елда филиалыгызның бу эштә өлеше ниндирәк?

– Татарстанда язгы кыр эшләре элеккечә үк алып барыла. Федераль Хөкүмәтнең һәм Татарстан җитәкчелегенең төпле сәясәте нәтиҗәсендә бу юнәлештә тоткарлыкларга һәм гадәттән тыш хәлләргә юл куелмый.

«Россельхозбанк»ның төбәк филиалы директоры буларак, авыл хезмәтчәннәренә финанс ярдәме буенча башкарылып килә торган эшнең әһәмиятен аерым бер горурлык хисе белән искәртеп үтәсем килә. Сүз уңаеннан, ел башыннан бирле төбәк филиалы агросәнәгать комплексына 4,9 миллиард сум күләмендә акча бирде. Шуның 4,5 миллиард сумы, ягъни 92 проценты – ташламалы ставка буенча.

Без авыл хуҗалыгында сезонлы эшләрне, элеккечә үк, ташламалы шартларда – 5 проценттан артмаган ставка буенча кредитлыйбыз. Авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә һәрвакыт ярдәм итеп киләбез. Алар бик мөһим эш башкара: илнең азык-төлек иминлеген тәэмин итә бит.

Филиалның агросәнәгать комплексын ташламалы кредитлаудагы өлешенә килсәк, әлегә ул 90% тәшкил итә. Шул исәптән кече хуҗалыклар буенча – 79%.

Авыл хезмәтчәннәренең банк ярдәме белән быел да мул уңыш җыеп алачакларына ышанам.

:: Дөньядагы вазгыять «Россельхозбанк» эшенә ничегрәк йогынты ясый? Ел башына билгеләнгән планнарны үзгәртергә туры киләме? Халык өчен ташламалы программаларда үзгәрешләр бармы?

– Хәзер берьюлы берничә ташламалы программа тәкъдим итәбез. Беренче чиратта, сезонлы кыр эшләренә ташламалы кредит. Моннан тыш, Россия Хөкүмәте карары нигезендә, агросәнәгать комплексындагы төп предприятиеләргә эшчәнлекләрен алып баруга ташламалы шартларда кредит бирелә. Әйтик, «Кызыл Шәрык Агрохолдингы» акционерлык җәмгыяте компанияләрен, төп предприятиеләргә ярдәм итү буенча федераль чаралар кысаларында, ташламалы финанслауга заявка хупланды.

Халык өчен дә ташламалар гамәлдә. Мәсәлән, балалы гаиләләр өчен дәүләт ярдәме нигезендә ипотека. Яшь гаиләләргә торак алуга ярдәм итүнең гаять мөһим булуын бөтен тирәнлеге белән аңлыйбыз.

:: «Россельхозбанк» ике ел элегрәк авыл хуҗалыгы җитештерүчеләре өчен тиңдәшсез мәйданчыклар булдырды. «Свое Фермерство» экосистемасы һәм «Свое Родное» маркетплейсы фермерлар арасында көннән-көн күбрәк популярлаша. Үз продукциясен интернет аша сатарга ниятләүче фермерларга нинди шартлар куела? Әлеге платформалар сезнең ышанычны акладымы? Аларның киләчәген ничегрәк күзаллыйсыз?

– «Россельхозбанк» авыл хуҗалыгы базарын цифрлаштыруга бик көчле этәргеч бирә. Авыл хезмәтчәннәре өчен «Свое Фермерство» экосистемасы махсус оештырылды. Банк тәҗрибәсен һәм алдынгы технологияләрне берләштерә ул. Экосистеманың төп максаты – катлаулы агротехнологияләрне гади тел белән аңлату, фермер хуҗалыкларына һәм агросәнәгать комплексы предприятиеләренә эшне автоматлаштыруга һәм моның өчен кирәкле сервислардан уңайлы цифрлы форматта файдалануга ярдәм итү. «Свое Фермерство» экосистемасы – авыл хуҗалыгында цифрлы хезмәтләр дигән сүз. Ул иң алдынгы тәҗрибәне, заманча технологияләрне һәм үзара аралашып эшләүне үз эченә ала.

«Свое Фермерство» (https://svoefermerstvo.ru/) агросервислардан, бизнеска ярдәм итү сервисларыннан, финанс һәм мәгълүмат хезмәтләреннән тора. Аерым алганда, әлеге тиңдәшсез проект фермерларга интернет аша тәүлек әйләнәсе ветеринар һәм зоотехниклар ярдәменнән файдалану мөмкинлеге бирә.

Бизнеска ярдәм итү сервисы шулай ук авыл хуҗалыгы җитештерүчеләренә бизнесны теркәүдә, онлайн бухгалтерия алып баруны оештыру, юридик консультация алу һәм продукцияне сертификацияләүдә булыша. Финанс сервислары ташламалы кредит алу яки расчет-касса хезмәтенә тоташу буенча бик җентекле мәгълүматлар бирә.

Хәзерге вакытта экосистемага төрле җитештерүчеләрнең дистәләрчә мең товары урнаштырылган. Шул исәптән 2 меңнән артыграгы – Татарстан фермерлары товары. Платформада авыл хуҗалыгы өлкәсендә гаять бай вакансияләр базасы да урын алган. «Россельхозбанк», яңа сервислар булдырып һәм маркетплейсны тулыландырып, экосистеманы даими үстерә.

«Свое Родное» (https://svoe-rodnoe.ru/) электрон сәүдә мәйданчыгының да агросәнәгать комплексы өчен әһәмияте гаять зур. Фермерларның табигый продукциясен интернет аша сату мөмкинлеге бирә ул. Электрон сәүдә мәйданчыгы табигый продуктларны сату өчен цифрлы киштә хезмәтен үти. Платформада Россиянең теләсә кайсы фермеры теркәлеп, үз продукциясенең каталогын булдыру һәм үзе җитештергән товарларны сату мөмкинлегенә ия. Россиянең төрле почмакларыннан 8,5 мең фермер шулай эшли дә инде.

Фермер хуҗалыклары өчен үзләренең товарын кулланучыларга турыдан-туры сату мөмкинлеге дигән сүз бу. Сатып алучылар бик тә уңайлы цифрлы кушымта аша фермер продукциясе ассортиментыннан үзләренә кирәклесен сайлап, аңа заказ бирә.

Моннан тыш «Россельхозбанк»ның «Свое за городом» (https://svoe-zagorodom.ru/) цифрлы мәйданчыгында фермерлар үзләренең агротурларын урнаштыра, экскурсияләрдә, дегустацияләр һәм кәсепчелек буенча мастер-классларда катнашуны тәкъдим итә ала. Бу авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә үз бизнесын төрләндерергә ярдәм итә.

Шулай итеп, банк булдырган цифрлы мәйданчыклар ярдәмендә фермерлар, башка ресурсларга вакытын әрәм итмичә, бер урында – үзләренең аккаунтында кирәкле барлык хезмәтләрдән файдалану мөмкинлегенә ия. Бу платформалар ышанычыбызны аклады, дип уйлыйм. Шул ук вакытта яңа сервисларны уйлап табу һәм гамәлгә кертү дәвам итә.

:: Әлеге платформалар – инде азу ярган фермерлар өчен. Шул ук вакытта сез яңа эш башлап җибәргән фермерларга да ярдәм итәсез. Банкның тагын бер тиңдәшсез проектларыннан берсе – «Школа фермера». Аннан ниләр көтәсез? Җиңүчеләрне сайлап алганда, иң элек нәрсәгә игътибар итәсез?

– «Школа фермера» – авыл хуҗалыгы өчен кадрлар әзерләү максатында, республика Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгын, профильле вуз, эре бизнес һәм фермерларны берләштерүче тиңдәшсез проект ул.

Төп үзенчәлеге шунда: биредә теория практика белән үрелеп бара. «Школа фермера» проектын Казан дәүләт аграр университеты белән берлектә тормышка ашырып киләбез. Университет лекторлары һәм чакырылган белгечләр югары уку йортында фермерларны бизнес серләренә өйрәтә. Эш барышында бик күп сораулар туа, шуңа күрә фермерларга ярдәм итү, ә иң мөһиме – күңелләрендә ышаныч тудыру мөһим. Биредә алар, бик якын тарафдарлар кебек, бер телдә сөйләшә.

Фермерларга аралашып эшләү кирәк. «Школа фермера»ның ике чыгарылышыннан соң шундый фикергә килдем: тыңлаучыларыбыз арасында төрле һөнәр ияләре бар, әмма аларның барысын да хуҗалык алып баруга омтылыш берләштерә. Төрле чараларда үз уңышлары турында берсен-берсе бүлдерә-бүлдерә сөйләүләре, киләчәккә планнары белән уртаклашулары минем өчен аеруча мөһим. Нәкъ менә шундый мизгелләрдә бу кешеләрнең чыннан да яраткан эш белән шөгыльләнүләрен бигрәк тә нык аңлыйсың.

:: Газетабызны асылда авылда яшәүчеләр укый. Шуңа күрә «Авыл ипотекасы»на да тукталып үтик. Авылларны үстерү өчен зур ярдәмгә әйләнде бит ул. Программа әле күптән түгел генә яңадан эшли башлады. Аның шартлары үзгәртелдеме, әллә элеккечә үк калдымы?

– «Россельхозбанк» 22 апрельдән янә авыл ипотекасына гаризалар кабул итә башлады. Ташламалы ставка шул ук дәрәҗәдә сакланып кала: авылда 3 процентлы кредит белән торак сатып алырга мөмкин.

Үзгәрешләргә килгәндә, болайрак: хәзер бу ипотеканы фәкать шәхси йорт төзүгә һәм әзер йорт сатып алуга гына тотарга мөмкин. Шул ук вакытта физик заттан җир кишәрлеге белән бергә сатып алына торган йортның «яше» 5тән артмаска тиеш. Ә инде юридик заттан сатып алганда өчтән артып китмәве шарт. Шулай ук газлаштыру таләбе дә юкка чыгарылды. Яңа таләп: сатып алынган йортта даими теркәлү кирәк. Аны өч айга бер тапкыр раслап тору сорала.

Авыл ипотекасы «Авыл территорияләрен комплекслы үстерү» программасы кысасында гамәлгә ашырыла. Ул 21дән 75 яшькә кадәрге кешеләргә бирелә. Ипотека акчасын авыл җирлегендә, ягъни халык саны 30 меңнән артмаган сала-бистәләрдә торак сатып алуга тотарга мөмкин. Кредитның минималь күләме – 100 мең сум. 25 елга кадәр бирелергә мөмкин.

«Россельхозбанк» 2020 елның языннан бирле авыл ипотекасы буенча халыкка 5,5 миллиард сум кредит бирде инде. Татарстанда 2500дән артыграк гаиләнең яшәү шартларын яхшыртуга ярдәм итте бу.

:: Шундый хәлне күз алдына китерик: авылга күченеп, анда бизнес ачасым килә ди. Бу очракта дәүләттән нинди ярдәмгә өмет итәргә була?

– Инде алда әйтеп үтелгәнчә, яңа эш башлаучыларга «Школа фермера» проекты зур ярдәм күрсәтә. Анда үз бизнесы проектларын уңышлы яклаучыларга эшләрен үстерүгә грантлар алу мөмкинлеге бирелә. Шул ук вакытта мәктәптә укыту программасы белем дәрәҗәсе һәм эш тәҗрибәсе төрлечә булган кешеләргә исәпләнгән. «Школа фермера»да фермер бизнесын нульдән башлап кору яки инде оештырылган хуҗалыкны үстерү буенча күпкырлы белемнәр бирелә. Анда уку бушлай. Мәктәпне тәмамлап чыгучыларга программаны үзләштерү, диплом эшен яклау йомгаклары буенча дәүләт үрнәгендәге дипломнар тапшырыла һәм үзләренең хуҗалыгын үстерү өчен грантка заявка тапшыру мөмкинлеге бирелә.

Кыскасы, «Россельхозбанк» заманча, технологик, нәтиҗәле авыл хуҗалыгын булдыруга актив төстә ярдәм итеп килә. Татарстан филиалы фермерларның югары күрсәткечләргә ирешүе өчен мөмкин булганның барысын да эшли.

КӘГАЗЬДӘН... КЕШЕ БИЕКЛЕГЕ МӘЧЕТ

ОРИГАМИ ЫСУЛЫ БЕЛӘН ТӨЗЕЛГӘН БУ МАКЕТКА 86 МЕҢ МОДУЛЬ КИРӘК БУЛА

Балтач үзәк мәчетенә кергән саен, музеенда урнашкан әлеге зур макетка һәркем игътибар итә. Бердән, зал уртасында, икенчедән, шактый биек һәм матур. Читтән караганда аның нәрсәдән эшләнгәнен дә чамалап булмый. Янына килгәч кенә, оригами ысулы белән гап-гади кәгазь битләреннән бөкләп ясалган булуын күреп гаҗәпләнәсең. Баксаң, авторның бу бердәнбер генә хезмәте түгел икән.

Әлеге гүзәллекне тудыручы – Балтачта яшәүче Таһир абый Садыйков. Аның бу шөгыль белән ничек кызыксынып китүен сорашам.

– Мин – белемем буенча төзүче, техникум тәмамлаганнан соң күп еллар районлагы төзелеш оешмасында мастер булып эшләдем. 2010 елда инфаркт кичердем, аннан йөрәккә катлаулы операция булды. Авыр эшләр эшләргә ярамый башлады. Безнең районның Чепья авылындагы «Наз» тернәкләндерү үзәгенә баргач, оригами ысулы белән сувенирлар ясап күрсәттеләр. 2011–2012 еллар иде бу. Эшләп карагач, ничектер ул мине тынычландырган кебек тоелды. Кызыксынып киттем, башта махсус өйрәтә торган китап сатып алдым, аннан интернет аша өйрәнә башладым…

Башта әле ул гадирәк сувенирлар: кошлар, җәнлекләр, картиналар ясый, аннан самавыр-чынаякларны берничә төрле итеп эшли (әле арасында тасмалардан төрле-төрле кәрзиннәр дә үрергә өлгерә)… Заманында үзләре төзегән мәчеткә намазга йөри башлагач, күңелендә шушы мәчетнең макетын эшләү нияте туа. Тик баштарак шактый уйланып йөри, тәвәккәлләми.

– Уйладым дип кенә эшләп булмый бит әле аны, – ди Таһир абый. – Төзүче буларак әйбәт беләм: масштабларын бөтенесен туры китерергә кирәк. Башта фотога төшердем, аннан компьютерга кертеп, исәпли, саный башладым. Ничә төрле вариантта гына эшләп карамадым, барып чыкмады…

Ничә тапкыр сүтеп бетереп, өр-яңадан кора башлавының төгәл исәбен дә хәтерләми үзе. Әмма бер ниятләгәч, бераз туктап тора да кабат үҗәтләнеп тотына. Ахыр чиктә горизонталь буенча бер кирпечкә ике модуль (бөкләнгән кечкенә кәгазьләр) исәбеннән, вертикаль буенча бер кирпечкә бер модуль исәбеннән эшли. Әле бит тәрәзә кырлары тагын да катлаулы, күренеп торган рәткә аерым, яшерен рәткә тагын аерым исәп кирәк була. Ике ел ярым ясый бу макетны Таһир абый. Ни дисәң дә, кәгазь мәчет кечкенә түгел: биеклеге ике метр 80 сантиметр, киңлеге-озынлыгы 1,80 х 2,80 м.

– Макетка күпме кәгазь китте, исәпләмәдегезме? – дим.

– Бөтенесе 86 мең модуль, А4 форматындагы 5500 ак һәм төсле битләр, майонез чиләге белән егермедән артык чиләк җилем китте, – ди ул. – Җәмәгатем Гөлфирә белән улым Илнур модульләр ясарга булышты, дусларым Фәләхетдин Гарәфетдинов, Мансур Шәрәфетдинов, мәрхүм Хөсәен Камалов беркеткәндә булыштылар. Тотып торырга да кирәк бит. Ясап бетергәч, үзәк мәчетнең имам-хатыйбы Рамил хәзрәткә әйткән идем, килеп карады да бик ошатты, мәчет музеена алабыз, диде…

Аннан соң ул 1,8 метр биеклектәге Сөембикә манарасын ясый. Анысына да хуҗа тиз табыла – берничә ел инде район үзәк китапханәсе бизәге булып балкып утыра. Бүген Таһир абый Сөембикә манарасының «игезәк туганы»н ясый башлаган. Анысы кечерәк булачак, ди.

– Мәскәүдәге, Кызыл мәйдандагы Василий Блаженный соборын да ясаган идем. Аның өчен орыштылар да инде, – ди Таһир абый. – Үзең мөселман, үзең шундый собор ясагансың дип. Сәнгать әсәре буларак бик әсир иткән иде ул мине. Бик катлаулы да бит, ясап булырмы икән дигән кызыксыну да көчле булды. Интернетта шуны оригами ысулы белән ясаган бер кешене тапкан идем. Сызымын-исәпләрен җибәрегез әле, мин дә ясамакчы идем дигәч, шул-шул исәпкә 45 мең сум акча күчерегез, аннан җибәрәм, дип җавап бирде. Үзем эшләдем һәм ун айда ясап та бетердем. Райондагы ике чиркәүгә тәкъдим итеп караган идем, алучы, кызыксынучы булмады, гаражымда тора…

Гараж димәктән, ул – Таһир абыйның остаханәсе дә. Кышларын өйдә эшләсә, җәйләрен шунда күченә. «Көннәр буе аны гына эшләмим, әмма буш вакытым булды исә, куллар үзеннән-үзе шушыңа үреләләр, – ди үзе. – Бер сәгатькә 150ләп кәгазь бөтерәм, аккошларны бер сәгать эчендә ясап бетерәм… Заказлар күп булмый, үземнең дә эшемне рекламалап, заказга эшлим дип әйткәнем юк инде, барыбер ишетәләр, киләләр. Җиңүнең 75 еллыгына балалар бакчаларына, зур итеп, Җиңү орденын ясап бирдем…

Шунысына сөенә Таһир абый: Балтач гимназиясенең 4 нче сыйныфында укучы оныгы Лиана да бабасының шөгыле белән бик кызыксына икән. Ул ясаган матур вазаны истәлеккә сакласа, аккошларны әллә ничәне ясады инде, ди, горурланып.

Гөлсинә ХӘБИБУЛЛИНА

922
2022

1100 еллыкка – 1100 имам

XII Бөтенроссия татар дин әһелләре форумында быел әнә шулкадәр кунак катнашачак. Алар Россиянең 76 төбәгеннән һәм 7 чит илдән килер дип көтелә.

Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты рәисе Данис Шакиров сүзләренә караганда, быелгы форумга Донецк һәм Луганск республикаларыннан да кунаклар көтәләр. Беренче тапкыр Хакасия белән Еврей автономияле округыннан да делегатлар чакырылган. «116 кешелек иң зур делегация ут күршеләребез – Башкортстаннан киләчәк», – диде Данис Шакиров.

Иң өлкән делегат Калининград өлкәсеннән 97 яшьлек Хәким ага Бикеев булачак. Иң яшь делегат Пенза өлкәсеннән киләчәк. Камил хәзрәт Юсеевка – 19 яшь.

Уникенче ел рәттән уздырылучы форумның быелгысы Идел Болгарстанында ислам дине кабул ителүгә 1100 ел тулуга багышлана. Форум делегатлары 20 майда Җәмигъ мәчетенә нигез ташы салу тантанасында катнашачак. Яңа мәчет нигезендә меңләгән кеше бергәләп җомга намазы укыячак. 21 май көнне форум делегатлары Изге Болгар җыены тантанасында да катнашачак. Өч көн дәвамында алар «Russia Halal Expo 2022» күргәзмәсе белән дә танышачак.

Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты рәисе урынбасары Марс Тукаев сүзләренә караганда, быелгы форумда катнашырга теләк белдерүчеләр бик күп булган. Ләкин аларның барысын да кабул итеп бетерү мөмкин түгел. Киләсе елга форумның форматын үзгәртү турында да уйланалар.

– Унике ел дәвамында үткәрелеп килә торган әлеге җыенның исеме безнең максатыбызны да чагылдыра. Милли тормыш һәм дин ул – аерылгысыз төшенчәләр. Имамнар халык белән һәрвакыт тыгыз элемтәдә. Милли оешмалар булмаган төбәкләрдә дә мәчетләребез, мәхәлләләребез эшләп килә. Шул рәвешле без аларны үзебезнең эшчәнлеккә җәлеп итә алдык, – ди Марс Тукаев.

«ХӘЗЕР КИРЕ ӨЙГӘ ИЛТЕГЕЗ...»

МӘСКӘҮДӘ РЕНАТ ИБРАҺИМОВНЫ СОҢГЫ ЮЛГА ОЗАТТЫЛАР

Аны яратмаган кеше юктыр. Гади, зыялы, тормышка үлеп гашыйк. Россиянең халык артисты Ренат Ибраһимовны якыннан белгән кешеләр җырчыны шулай дип искә ала. 75 яшьлек юбилеен гөрләтеп уздырырга ниятләп йөргән кешенең үлеме кемне генә тетрәндермәде икән?!

Ренат Ибраһимов 19 майда Мәскәүнең «Градский Холл» театрындагы концертта чыгыш ясарга тиеш була. Шушы чарага кадәр берничә көн кала – 14 майда репетициядә катнаша. Соңгы репетициясенең видеосын концертның продюсеры социаль челтәргә дә куйган. Анда легендар җырчы Муса Җәлилнең «Юллар» шигыренә композитор Радмир Шәйхетдинов иҗат иткән җырны кабатлый:

«Юллар, юллар! Мине туган йорттан
Аерып ерак алып киттегез.
Җитәр инде, озак кунак булдым,
Хәзер кире өйгә илтегез...»

«Нинди моңсу җыр...» Продюсерга шулай ди ул. Ә берничә сәгатьтән йөрәге тотып ала да тибүдән туктый...

vk.com

«Һәр нәрсәдән яхшылык эзләде...»

Татарстанның халык шагыйре Разил Вәлиев Ренат Ибраһимов белән тәүге тапкыр төгәл 50 ел элек күрешә.

– Кемнең-кемнең, әмма Ренат Ибраһимовның бу дөньядан китүен күз алдына китерә алмый идем. Аның энергиясе, куәте ташып торды. Күпме хыяллары, омтылышлары, проектлары чынга ашмый калды...

Мин аны бик күптәннән беләм. Тәүге тапкыр моннан 50 ел элек, 1972 елның маенда очраштык. Безне ул вакытта яшь композитор Рәшит Абдуллин таныштырды. «Бер көй язган идем, шул көйгә сүзләр кирәк. Мин аны Ренат Ибраһимовны күздә тотып яздым, ризалашсаң, өчәү бергә очрашып та алырбыз», – дип тәкъдим итте. Җырның сүзләрен язгач, очрашырга сүз куештык. Ул чакта Ренат Декабристлар урамында яши иде, беренче очрашуыбыз да шунда булды. Һәм шулай итеп «Төсле җыр» язылды. Соңгы көннәренә кадәр җырлады ул аны. Рәшит исән чакта бергәләп санаган идек – аның репертуарында без язган 17 җыр булган икән.

Шул чакта ук аның бер сыйфаты күңелемә кереп калган. Ренат җырны башкарып кына калмыйча, аны иҗат итүдә бик актив катнашты. Без гел бергә эшләдек. «Моны болай итсәк, ничек булыр икән?» – дип, җырларыбызга үз төзәтмәләрен, үз өлешен кертте ул.

Мин электән Ренатның үземдә булмаган күркәм сыйфатларын хөрмәт иттем. Без яшьләр булсак та, Ренат олпатлыгы белән аерылып торды. Ул бит инде – хәрбиләр гаиләсендә Татарстаннан еракта туып, татар мохитеннән читтә үскән бала. Дөньяны күп күргән егет. Ул чорда без бик күп нәрсәгә тәнкыйть күзлеге аша карарга тырыша идек. Ренат та бар нәрсә белән дә килешмәде, үзенә ошамаганны ипләп кенә, берәүне дә рәнҗетмичә әйтә белде. Без вакыйгаларның, кешеләрнең җитешмәгән якларын эзләсәк, ул матуррак, камилрәк якларын күрә белде, һәр нәрсәдән яхшылык эзләде. Бездә бит кеше кадере бик югары дәрәҗәдә түгел, ә аның өчен ул гаять кыйммәткә ия иде.

Ул һәр кешегә олы затка караган кебек карады, ә күңеленә хуш килмәгән кешеләр белән аралашмады. Безне бу яктан бик күп нәрсәгә өйрәтте Ренат.

Ул дин юлында үзен бик озак эзләде. Исламга да 40 яшьтән соң гына кайтты. Биш вакыт намазын укыды. Динне бик тирән өйрәнде.

– «Мин исламга кайтмыйча булдыра да алмый идем. Беренчедән, җан да, кан да тартты. Икенчедән, әтием дә Ислам исемле бит минем», – дигәнен хәтерлим, – дип искә алды Разил абый.

Алар әле берничә атна элек кенә матур планнар корган була: Ренат Ибраһимовның барлык әниләргә багышланган җыр иҗат итү теләген чынга ашырырга ниятлиләр. «Сүзләрен язарга вәгъдә бирдем. Җыр да өлгермәде, Ренат та китеп барды...»

«Тавышы ничек ягымлы, холкы да шундый булды»

Ренат Ибраһимовның дусты, курсташы, Россиянең халык артисты Зилә Сөнгатуллинаның зур үкенече калган.

– Татар халкының данлыклы җырчысын соңгы юлга озатырга Татарстаннан делегация бармады. Президентыбызның сүзләрен ишеттек, әмма, кызганыч, Мәдәният министрлыгы Мәскәүгә сәфәрне оештыра алмады. Бик зур үкенеч бу... Ул бит гади җырчы гына түгел, чын җырчы иде! – дип сөйләде ул безгә. – Ренат үзе белән күңелемнең яртысын алып китте. Без аның белән бик яхшы дуслар булдык, гомер буе аралашып яшәдек. Бергә укыдык, бергә эшләдек. Мәскәүгә киткәч тә, араларыбыз өзелмәде.

Ул үзен кабатланмас тавышлы, искиткеч тембрлы җырчы, оста актер, шәп рәссам буларак та күрсәтте. Казанда опера театрында эшләгәндә, без аның белән «Любовный напиток», «Евгений Онегин» операларында төп рольләрне башкардык. Тавыш дисеңме, буй-кыяфәтме, сәхнәдә үзен тотышы – бар яктан килгән артист иде ул. Соңгы көннәренә кадәр шушы биеклеген саклый килде.

Яшьли өйләнде Ренат. Ике гаиләсе, кызганыч, таркалды. Үз бәхетен соңыннан барыбер тапты ул. Өченче хатыны Светлана белән дүрт бала үстерәләр иде, әтисез калды балакайлар. Шуларны уйлыйм да, йөрәгем әрни.

Аныкы кебек тавыш Татарстанда гына түгел, Россиядә дә юк иде. Мин аны күренекле җырчылар Мөслим Магомаев, Георг Отс, Павел Лисициан белән генә чагыштырырга мөмкин дип уйлыйм. Ренатның тавышы ничек ягымлы, холкы да шундый булды. Кем генә булмасын, һәр кеше белән тиешле дәрәҗәдә аралаша белде, ихлас һәм ачык иде. Беләсездер инде, соңгы елларда дин юлына басты, безнең алда дәрәҗәсе тагын да артты.

Бик бәхетле яшәде Ренат. Балаларын башлы-күзле итеп, аларны аякка бастырырга хыяллангандыр, җаныем. «120гә кадәр яшим әле мин», – дип әйтергә ярата иде. Һәм яшәр иде дә ул! Соңгы елларда да физик яктан үзен бик карады, вокаль яктан да яхшы формада иде. 20 ноябрьдә юбилей концерты булырга тиеш иде аның. Дәртләнеп, шуңа әзерләнеп йөрде. 10 минут эчендә киткән бит ул...

«Гаять гади кеше иде...»

Бөтен кешене исеме белән белеп, һәркем белән исәнләшеп йөрде. Хезмәттәшебез Габделбәр Ризванов кайчандыр күршесе булган Ренат Ибраһимовны шулай искә ала.

– Минем Ленинградта политмәктәптә укыган чагым. Ренат Ибраһимов шунда 10 көнлек концертлар белән килде. Без моны белеп алдык та тулай торакка кунакка чакырдык. Ул соңгы концертыннан соң килергә вәгъдә бирде һәм безне дә тамаша кылырга чакырды. Кичәдән соң тулай торакка кайтып, җырчыны кунак иттек. Өстәл янында озак утырмады, балконга чыкты да: «Ай, былбылым, вай, былбылым», – дип җырлап җибәрде. Шул арада вахтер апа менеп җитте дә: «Вы что делаете? Прекратите! Руководству доложим!» – дип куркытырга тотынды. Без дустым Хәлим Гайнуллин белән, куарлар инде, дип уйлаштык.

Икенче көнне иртәнге тугызынчы яртыда ректор янына керергә куштылар. Хәлим шунда иде инде. Ректор: «Ну, рассказывайте, что случилось?» – диде. Берничә тапкыр сорады, тавышын да күтәреп карады. Шуннан Хәлим торды да: «Борис Григорьевич, это же Ренат Ибрагимов был», – диде. Ректорыбызның күзләре шар булды. Баксаң, алар татар милләтеннән булган хатыны белән Ренатның концертын тамаша кылып, аңа сокланып кайткан булганнар. Шулай итеп, Ренат безне куылудан саклап калды. Борис Григорьевич әле соңыннан да: «Как дела, мои татары?» – дип, безнең белән күрешеп йөрде.

Ренат 80 нче елларда «Кәҗә бистәсе»ндә безнең күрше йортта тора иде. Аралашып яшәдек. Әтисе минем якташ булгач, Кукмарага да кайтып килдек. Гомумән, гаять гади кеше иде ул. Бөтен кешене исеме белән белеп, һәркем белән исәнләшеп йөрде. Барыбыз белән дә яхшы мөгамәләдә булды. Татарстаннан читтә үссә дә, татарча бик матур сөйләшә иде ул. Безнең белән аралашып, телен тагын да шомартырга тырышты. «Сезнең белән кызык булганга түгел, туган телемне яхшылап өйрәнәсем килгәнгә аралашам», – дип тә әйткәне истә.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

КАЙГЫ УРТАКЛАШУ



РЕНАТ ИСЛАМ УЛЫ ИБРАҺИМОВ
(20.11.1947 – 14.05.2022)

Татарстан Республикасы җәмәгатьчелеге авыр югалтуга дучар булды. РСФСР һәм ТАССРның халык артисты Ренат Ислам улы Ибраһимов 14 май көнне 75 нче яшендә арабыздан мәңгегә китте.

Ренат Ибраһимов – бөтен дөнья күләмендә миллионнарча тамашачының күңелен яулаган легендар җырчы. Татар башкару сәнгатенең тулы бер дәвере аның исеме белән бәйле. Күренекле җырчының иҗаты берничә буын тамашачыны әсир итте. Ул бүгенге күп кенә җырчылар өчен дә өлге булып тора.

Ренат Ибраһимов 1947 елның 20 ноябрендә Украина ССРның Львов шәһәрендә дөньяга килә. Берничә елдан соң Ибраһимовлар гаиләсе Казанга күченә. Мәктәп елларында малайның җырга уникаль сәләте сизелә башлый. Урта белем, музыка белеме алгач, Идел буе хәрби округының җыр һәм бию ансамбленә эшкә урнаша, шуннан соң ялгыз чыгыш ясый башлый.

Ренат Ибраһимов 1973 елда Казан дәүләт консерваториясен тәмамлаганнан соң Муса Җәлил исемендәге Татар опера һәм балет академия театры солисты булды. Сәхнәдә ул «Князь Игорь», «Кармен», «Фауст», «Евгений Онегин», «Пиковая дама» операларында төп партияләрне башкарды.

Музыкаль бәйгеләрдәге күп кенә җиңүләре аңа эстрада җырчысы сыйфатында үрләр яулауга юл ачты. Ренат Ибраһимов 1974 елда Бөтенсоюз эстрада артистлары бәйгесе лауреаты исеменә лаек булды. Бу вакыйгадан соң бер ул узгач, «Красная гвоздика» җыр бәйгесендә төп бүләк яулау бөтен ил күләмендә танылуына китерде.

1988 елда ул Габдулла Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясенә эшкә күчте. Филармониядән киткәч, «Сәфәр» татар милли үзәгенә җитәкчелек итте.

Ренат Ибраһимов 1999 елда үзенең Җыр театрын булдырды. Артист биш телдә җырлады. Аның репертуары йөзләрчә халык, эстрада һәм опера композицияләреннән тора иде. Тамашачыларны искиткеч матур баритон тавышы һәм зәвыгы белән әсир итте.

Асылда аның һәр җыры халыкта популярлык казанды. «Что так сердце растревожено», «Лада», «Мне хорошо с тобой», «В краю магнолий», «Шагает солнце по бульварам» кебек җырлары аеруча яратып кабул ителде.

Ренат Ибраһимов иҗтимагый-агарту эшчәнлеге белән актив төстә шөгыльләнде, киногa төште, 40тан артыграк музыкаль җыентык режиссеры булды. Үсеп килүче буынның җырлау осталыгын үстерү һәм тәрбияләүгә зур игътибар бирде.

2017 елда, үзенең 70 яшьлек юбилее уңаеннан, Кремль сараенда «По морю жизни» дигән автобиографик концертын үткәрде.

Ренат Ислам улының югары дәрәҗәдәге һөнәри осталыгы һәм намуслы хезмәте күп кенә дәүләт бүләкләре белән билгеләнде. Алар арасында – «Дуслык» ордены, «Казанның 1000 еллыгы истәлегенә», «Фидакарь хезмәт өчен», «Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы оештырылуга 100 ел» медальләре, Татарстан Республикасы Мактау грамотасы. Габдулла Тукай исемендәге Республика премиясе лауреаты булды.

Ренат Ислам улы Ибраһимов эшкә гаять зур җаваплылыгы, хезмәт сөючәнлеге, кешеләргә карата игътибарлы мөгамәләсе, үз эшенә чиксез тугрылыгы белән аерылып торды. Күренекле артист, талантлы кешенең якты истәлеге күңелләребездә мәңгегә сакланыр.

Р.Н.Миңнеханов, М.Ш.Шәймиев, Ф.Х.Мөхәммәтшин, А.В.Песошин, Ә.Ә.Сәфәров, Р.К.Әхмәтшин, В.Г.Шәйхразыев, И.Х.Әюпова, И.Р.Метшин, Ш.Р.Агеев, Р.С.Мөхәммәтҗанов

Спорт

УЕННАН УЙМАК ЧЫКМАГАЕ

Футбол сөючеләр бу атнада «Рубин» белән Уфа арасындагы очрашуны бушлай карый алачак. Билет бәясен команда уенчылары һәм тренерлары түли. 21 майда узасы матч тарихи вакыйгага әверелергә мөмкин. Җиңелгән очракта, Казан командасына премьер-лигадан төшеп калу яный.

Уеннан уймак чыкмагае. Узган якшәмбедә «Рубин» Екатеринбургта 0:3 исәбе белән «Урал»га оттырды. Көндәшләрнең бер тубын Казан командасында үзенә урын таба алмаган Олег Шатов кертте. Моңа өстәп, ул тагын бер нәтиҗәле пас бирде. Казан командасында исә үз артыннан башкаларны ияртә алырлык футболчы табылмады. Безнекеләр бернинди каршылык күрсәтә алмады һәм бу сезонда 16 нчы очрашуда оттырды. «Рубин»ның премьер-лигада бу кадәр очрашуда оттырганы юк иде.

Антирекордлар моның белән генә бетми әле. Быел Казан командасы капкасына 53 туп керттеләр. Шул рәвешле, кайчандыр ике мәртәбә чемпион булган һәм Европаны шаулаткан команда турнир таблицасында 14 нче урынга төште. Тагын бер җиңелү һәм безнекеләр премьер-лига белән хушлашырга мөмкин. Сезонның соңгы матчын «Рубин» бу шимбәдә үз кырында «Уфа»га каршы уздыра. Күршеләр – 15 нче урында. Җиңелгән команда иң көчлеләр арасыннан төшеп калырга тиеш булачак. Барысы да бик гади. Дөрес, көтелмәгән хәлләр дә булырга мөмкин. Премьер-лигада үзгәртеп кору уздыру, әйтик, командалар санын арттыру тәкъдимнәре дә еш яңгырый. Ул чакта инде «Рубин» беркая да китмәячәк. Дөрес, монысы әлегә һавадагы торнага өметләнү кебек. Ник дигәндә, спорттагы вакыйгалар дөньядагы хәлләргә нык бәйле.

«Рубин» җиңелүе белән тәмамланган матчлардан соң Леонид Слуцкий гадәттә уңышсызлыкның төп сәбәбе итеп чит ил уенчыларының кайтып китүе, ә яшь егетләрнең тәҗрибәсе юклыгы турында сөйли. Екатеринбургта исә ул тамашачыдан ярдәм сорады. «Алар килеп, безгә ярдәм итсә генә җиңә алачакбыз», – диде ул. Тик килерләр микән? Бу сезонда Казан командасы футбол җанатарларыннан читләшү өчен кулдан килгәннең барысын да эшләде. Уфага каршы узасы матчка керү бушлай булган өчен генә шимбә кичендә «Ак барс-Арена» трибуналарының халык белән тулачагы шик уята. Мавыктыргыч уенны җанатарлар акча түләп карарга да риза.

rubin-kazan.ru

	команда	очко
1	Зенит	65
2	Динамо	53
3	Сочи	43
4	Краснодар	49
5	ЦСКА	47
6	Локомотив	45
7	Ахмат	41
8	Крылья Советов	41
9	Ростов	38
10	Спартак	38
11	Нижний Новгород	30
12	Урал	30
13	Рубин	29
14	Химки	29
15	Уфа	27
16	Арсенал	23

Кайбыч белән Теләче җиңде

Иң яхшы яшь волейболчылар Кайбыч һәм Теләче районнарында яши. Казанда Татарстанның мәктәп волейбол лигасының җиңүчеләре ачыкланды. Иң көчле командаларны Дәүләт Советы Рәисе, республиканың волейбол федерациясе президенты Фәрит Мөхәммәтшин тәбрикләде.

Узган сезон ярышында 730 мәктәптән 21 меңнән артык укучы чыгыш ясаган. «Безнең лигада 4 мең команда бар. Алар 7 ай эчендә 7300 очрашуда уйнады. Мондый күрсәткечләр башка спорт төрләрендә хәтта өлкәннәр арасында узучы турнирларда да сирәк очрый, – диде Фәрит Мөхәммәтшин. – Мәктәп лигасы волейбол гаиләсенә әверелде. Балалар, аларның әти-әниләре, укытучылар, тренерлар, хөкемдарлар, профессиональ клублар, дәүләт органнары барысы бергә укучылар спорт белән шөгыльләнсен, шул рәвешле сәламәт тормыш рәвешен алып барсын өчен тырыша. Былтыр 2024 елга кадәр мәктәп спортын үстерү буенча федераль программа кабул ителде. Анда мәктәпләрдә спорт клублары һәм лигалар оештыру турында сүз бар. Без исә мәктәп волейбол лигасы оештырып, бу эшкә 4 ел элек үк алындык».

Финал турнирында мәктәп, район һәм зона ярышларында уңышка ирешкән 6 егетләр һәм 6 кызлар командасы чыгыш ясады. Иң көчлеләрне «Санкт-Петербург» волейбол үзәгендә ачыкладылар. Егетләр арасында Кайбыч районының Федоровское мәктәбе командасы җиңү яулады. Кызлар турнирын исә Теләче районының Шәдке мәктәбе командасы отты. Сентябрь аенда алар Россиянең мәктәп волейбол лигасында чыгыш ясаячак.

tatarstan.ru

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 7061 данә
Гомуми тираж – 16033 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 267

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+